МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.06.2020 г.Казань № 454.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 15 июлендә 6763 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 20 ноябрендәге 1064 номерлы «Инвалидларны эш белән тәэмин итү дәвамында озатып баруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган Инвалидларны эш белән тәэмин итү дәвамында озатып баруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 20 ноябрендәге 1064 номерлы «Инвалидларны эш белән тәэмин итү дәвамында озатып баруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган Инвалидларны эш белән тәэмин итү дәвамында озатып баруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына китерелгән үзгәрешләрне (Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.05.2019 ел № 328, 14.11.2019 ел № 1018, 31.03.2020 ел № 216 боерыкларында кертелгән үзгәрешләр белән) расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.А. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 23 июнендәге 454 номерлы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
2018 елның 20 ноябрендәге 1064 номерлы «Инвалидларны эш белән тәэмин итү дәвамында озатып баруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»
боерыгы белән расланган Инвалидларны эш белән тәэмин итү дәвамында озатып баруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.7 пунктта:

1 пунктчаның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Министрлыкның рәсми сайтында, Интернет челтәрендә, мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.6, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләрне үз эченә ала;»;

2 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең рәсми сайтында (http://www.mtsz.tatarstan.ru);»;

1.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.9 пунктта:

икенче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә булдырылган» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында булдырылган» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законы (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза формасы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы «Халыкны эш белән тәэмин итүдә булышлык өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучының шәхси эш бланк формаларын раслау турында» боерыгы (алга таба - 19.02.2019 ел № 90н боерыгы) белән расланган»;

2 бүлектә:

2.1 пункттагы «Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы .Россия Федерациясе Законының 7.1-1 ст. 1 п. 8 пп. (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү турында Закон)»;

2.2 пунктының «Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «518н номерлы Федераль стандарт» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 3 августындагы 518н номерлы боерыгы белән расланган Инвалидларны эш белән тәэмин итүгә булышлык итү буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандарты (алга таба - 518н номерлы Федераль стандарт)» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында «63-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль закон (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктның «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында «Федераль закон» сүзләрен «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

2.15 пункттагы «Хезмәтне яисә таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасында «880 номерлы тәртип» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 декабрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү тәртибе» сүзләренә алмаштырырга.